**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

ПГ-12 17.03.2025

Актаныш муниципаль районы Башлыгының 2014 елның 30 октябрендәге ПГ-51 номерлы «Актаныш муниципаль районы рәсми сайтының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча бүлекләрен урнаштыру һәм тутыру таләпләрен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башлыгының 2014 елның 30 октябрендәге ПГ-51 номерлы Актаныш муниципаль районы рәсми сайтының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча бүлекләрен урнаштыру һәм тутыру таләпләрен раслау турында»гы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы рәсми сайтының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча бүлекләрен урнаштыру һәм тутыру таләпләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. II бүлекнең 1 пунктында:

а) 2 абзацта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы коррупциягә каршы көрәш советы» сүзләрен «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 15 абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

в) 1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 1.1. «Татарстан Республикасы Рәисенең коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе" гиперссылкасы буенча кергәндә Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) рәсми сайтының тиешле бүлекчәсенә керү гамәлгә ашырыла»;

г) 1.14 пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Муниципаль район Башлыгы Л.Р.Зарипов